ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 июнь 2016 ел. № 3238

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге яшел утыртмаларны карау һәм саклау турында» 2007 елның 29 маендагы 1978 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге ФЗ-131 санлы Федераль законның 16 маддәсе, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 февралендәге 7-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсе, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын оештыру турында» 2006 елның 19 октябрендәге 15/8 нче карары, закон бозуны бетерү турында 2015 елның 15 июнендәге 10-14-2015 санлы гариза нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге яшел утыртмаларны карау һәм саклау турында» 2007 елның 29 маендагы 1978 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлекне 2.14 һәм 2.15 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.14. Кисү – агачлар һәм куаклыклар киселә торган тиешле җирләрдәге яки җир участокларындагы агачларны кисү.»;

«2.15. Ябалдашларны кисү (яшәртү өчен кисеп кыскарту) – үзлегеннән яшәрүгә сәләтле агачларның ботакларын һәм кәүсәсен 3,5-6,5 м биеклектә кисү.»;

2) 3.4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- ел саен (планлы) бәяләү – елга бер тапкыр»;

3) 3.10 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тикшерү тәмамланганнан соң ике нөсхәдә акт төзелә, бер акт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрелә. Тикшерү

нәтиҗәләре, кирәкле оператив чаралар кабул итеялә торган эксплуатацияләүче оешмада саклана.»;

4) 4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Әлеге кагыйдәләрнең 4.4 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргән очракта, паспорт яңартылырга тиеш.»;

5) 4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Реестрны алып бару эшләрен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.»;

6) 5, 6, 7 бүлекләр үз көчен югалткан дип танырга;

7) 8 бүлекне яна редакциядә бәян итәргә:

«8 Яшел утыртмаларны кисү, аларның ябалдашларын кисү һәм утыртуны гамәлгә ашыру, компесацион яшелләндерү тәртибе

8.1. Яшел утыртмаларны кисү, аларның ябалдашларын кисү һәм утырту агачларны һәм куаклыкларны кисү, аларның ябалдашларын кисү һәм утырту өчен яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу комиссиясе тарафыннан бирелә һәм яшел утыртмаларны кисү, аларның ябалдашларын кисү һәм утырту хокукы бирә торган рөхсәт булган очракта башкарыла.

8.2. Яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу комиссиясе, яшел утыртмаларның урнашу урынын тикшерү акты нигезендә, агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, аларның ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт әзерли.

8.3. Агачларны һәм куаклыкларны кисү яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу комиссиясенең карары буенча заказ бирүче тарафыннан акчалата яки компенсацион яшелләндерү компенсацияләнә.

8.4. Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, аларның ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәтнең гамәлдә булу срогы, яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу комиссиясенең карары буенча, эшләрнең катлаулыгына һәм күләменә бәйле рәвештә ике елга кадәр билгеләнә. Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, аларның ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәтнең билгеләнгән срогы тәмамланганнан соң, ул заказ бирүченең гаризасы буенча озайтылырга мөмкин.»;

8) 9 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашырганда, яшел утыртмаларны кисү, аларның ябалдашларын кисү һәм (яки) утыртуны килешенү тәртибе»;

9) 9.1, 9.2, 9.3, 9.4, 9.7 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1 Түбәндәге документларны теркәп, төзелеш күздә тотылган участокны тикшерү турында яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу комиссиясе рәисе исеменә язылган гариза нигезендә:

- киселергә тиешле яшел утыртмаларны күрсәтеп, участокның якындагы төзелешләр яки башка ориентирларга кадәр схемасы;

- җир участогы күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса, җир участогына хокук билгеләүче һәм хокукны раслаучы документларның расланган күчермәләре;

- биналар һәм корылмалар төзегәндә алар габаритына эләгә торган яшел утыртмаларны кисү башкарылган очракта, расланган проект документлары;

- кагылышлы булган территорияләрнең хуҗалары белән яшел утыртмаларны кисү һәм күчереп утырту шартларын килешенү;

- утыртмаларны утыртканда яки күчереп утыртканда, җир эшләре үткәрүгә ордер ачып, инженерлык челтәрләре вәкилләре белән килешенү;

- башка кирәкле документлар;

- яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу комиссиясе заказ бирүче белән берлектә төзелеш күздә тотылган участокны тикшерә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча яшел утыртмаларның урнашу урынын тикшерү акты төзелә, анда агачлар һәм куаклыклар саны, аларның торе, агачларның диаметры, торышы, газоннар булу, үлән капламы, чәчәклекләр һ.б. күрсәтелә.»;

«9.2. Яшел утыртмаларның урнашу урынын тикшерү акты нигезендә, заказ бирүчегә, киселә торган яшел утыртмалар бәясенең Методикага туры китереп билгеләнгән исәп-хисабы әзерләнә (киселә торган яшел утыртмаларның бәясен түләгән очракта).»;

«9.3. Агачларны һәм куаклыкларны кисү өчен алынган акчалар гариза бирүче тарафыннан шәһәр бюджетына түләнергә тиеш.»;

«9.4. Инженерлык коммуникацияләренә капиталь яисә агымдагы ремонт эшләре барышында, инженерлык коммуникацияләре саклау зонасына эләгүче киселә торган яшел утыртмаларның бәясе түләтелми, ә ремонт эшләре вакытында, газоннарны һәм чәчәклекләрне торгызу заказ бирүче акчалары хисабына башкарыла.»;

«9.7. Яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу комиссиясенең карары буенча агачларны һәм куаклыкларны кискәндә, киселә торган яшел утыртмалар өчен түбәндәге очракларда акча алынмый яки компенсацион яшелләндерү башкарыла:

- корыган һәм һәлакәт тудырырга мөмкин булган агачларны кискәндә;

- санитар кисү эшләре үткәрелгәндә (үсенте хәлендә калган кыска декоратив агачларны, кыргый үсентеләрне, куе утыртмаларны кисү);

- яшел утыртмалар каплаган торак һәм торак булмаган биналарга норматив яктылык төшүне тәэмин иткәндә (тиешле дәүләт органнары күрсәтмәсе буенча);

- СНиП бозып утыртылган агачларны һәм куаклыкларны кискәндә;

- инженерлык коммуникацияләрендә авария эшләре үткәргәндә һәм аврияне һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетергәндә»;

10) 10 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Яшел утыртмаларны кисү, алрның ябалдашларын кисү һәм утырту эшләрен башкаруга төп таләпләр»;

11) 10.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.1. Агачларны һәм куаклыкларны кисү, аларның ябалдашларын кисү һәм утырту яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу комиссиясе тарафыннан

бирелгән агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, аларның ябалдашларын кисүгә һәм утыртуга рөхсәт булган очракта башкарыла.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы

В.А. Гаврилов